| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«18» декабрь 2020 ел № 19

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Генераль прокурорының «Прокуратура органнарының хокук чыгару эшчәнлеге һәм дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлекне яхшырту турында» боерыгы белән Балтач районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Норма авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең 2013 елның 14 ноябрендәге 92 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗановка йөкләргә.

Норма авыл
җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов